**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

16.01.2025 — № 31

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибен раслау турында» 2018 елның 31 маендагы 385 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 маендагы 385 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 1.1 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге тәртип эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибен билгели.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче — Ә.К. Габдуллин